ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
НОВОТРОИЦК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

КАРАР

«03» апрель 2024 ел Новотроицк авылы № 5

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге составына керүче Новотроицк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Новотроицк авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Новотроицк авылында гражданнар җыенын билгеләү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Тукай муниципаль районы «Новотроицк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Новотроицк авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында» нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Советының 2019 елның 08 ноябрендәге 41/1 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге составына керүче Новотроицк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына һәм 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Новотроицк авылында гражданнар җыены карарына үзгәрешләр кертү мәсьәләсе буенча 2024 елның 14 апрелендә 17.00 сәгатькә гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез үзгәрешләр кертергә ризамы:

1) түбәндәге редакциядә бәян итеп, гражданнар җыенына чыгарылган һәм кабул ителгән «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге составына керүче Новотроицк авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 17 ноябрендәге 1 номерлы гражданнар җыены карарына:

«- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту»;

«- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау»;

2) түбәндәге редакциядә бәян итеп, 2023 елның 17 ноябрендәге 2 номерлы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Новотроицк авылында гражданнар җыены карарының 1 пунктында икенче-өченче абзацында:

«- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту»;

«- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка ярдәмче станцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау»;

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча үткәрергә: Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы, Новотроицк авыл җирлеге, Новотроицк авылы, Ленин урамы, 11 йорт (Новотроицкий СДК бинасы).

4. Халык җыенын оештыручы итеп Татарстан Республикасы, Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.

5. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Новотроицк авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә махсус мәгълүмат стендларында, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (tukay.tatarsatan.ru) урнаштырырга.

6. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Тукай муниципаль районы
Новотроицк авыл җирлеге Башлыгы Д.М. Габделхаева